РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 26 нчы сентябре** **Чистай шәһәре** **№ 47/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2017 елның 10 февралендә кабул ителгән 17/7 номерлы “Муниципаль вазыйфаны биләүче затны һәм, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрне бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында”гы 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**Карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка түләү, Чистай муниципаль районы Советының “Пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль вазыйфаны биләүче затны һәм пенсиягә чыгу уңаеннан, муниципаль хезмәткәрне бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү турында»гы 2017 елның 10 февралендәге 17/7 нче номерлы карары белән расланган пенсиягә чыгу уңаеннан, бер тапкыр акчалата бүләкләү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктындагы“(картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукы бирә торган яшькә җиткәч, яисә “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында”гы 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләү)” сүзләрен “(2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә

житкәч, я вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе, яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгәч)” сүзләренә алмаштырырга.

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов